КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 март г.Казань № 245

Төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 8[1] өлеше, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясындагы 22 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы Татарстан Республикасы чикләрендә ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлекләр (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә урнаштырырга планлаштырыла торган төбәк әһәмиятендәге объектларны һәм башка капиталь төзелеш объектларын урнаштыруны, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән төзелеше, реконструкциясе тулысынча финанслана торган һәм Татарстан Республикасы белән уртак чиге булган Россия Федерациясенең ике һәм аннан да күбрәк субъектлары территорияләрендә урнаштырырга планлаштырыла торган төбәк әһәмиятендәге объектны урнаштыруны, реконструкцияләүне күздә тота торган төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын тикшерүгә һәм килештерүгә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы булып тора дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин